*Илһам бирче, каурый каләм*



# Яшь каләмче

№5
Гыйнвар
2024ел

**Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе МАОУ “СОШ №40**

Яңа ел каникуллары балалар өчен иң күңелле һәм мавыктыргыч мәл. Безнең мәктәп укучыларына каникулда бер дә күңелсезләнергә туры килмәде. Укучылар төрле кызыклы һәм файдалы чараларда, бәйгеләрдә катнаштылар, экскурсияләргә бардылар .



Күп итеп кар яуды, көчле бураннар булды. Табигать рәхәтләнеп үз көчен күрсәтте. Безнең укучылар, каникулда булуларына карамастан,үз мәктәп ишегалларын кардан чистарттылар. Бергәләп, саф һавада эшләве бик рәхәт булды.Шулай да, ни генә әйтсәң дә, карлы-буранлы кыш бик ямьле инде.

Авылда ял итүчеләр әби –бабаларына кар көрәргә булыштылар.биек-биек кар тауларында уйнадылар

Каникуллар тәмамланды. Укучылар ял итеп, яңа көч җыеп иң озын чирекне башлап җибәрделәр. Без аларны “4”ле, “5”ле билгеләренә генә укырлар дип өметләнеп калабыз.







***Әбиләр "каникулы"!***

Каникуллар бетте диеп,
Әби җиңел сулады.
Шушы бер атна эчендә,
Күрмәгәне калмады.
Оныклары китү белән,
Кереп диванга ауды.
Телевизорын кабызды,
Альяпкычын салып атты.
Ай-яй хәзерге балалар,
Дип сөйләнде узалдына.
Телефоннар кулларында,
Эшләү юк уйларында.
Колакларында наушник,
Әйтәсең,ишетмиләр.
Көннәр буе йоклыйлар да,
Төннәр буе йөриләр.
Әби,әби бәлеш пешер,
Синең коймагың тәмле.
Мантый яса әле бүген,
Пиццаң да искитмәле.
Әбекәем бүген кичкә,
Булмас микән кыстыбый,
Ансын иртәгә пешерсәң,
Бүген өчпочмак ярый.
Тиен кебек тәгәрмәчтә
.
Әйләнә әби көн буе.
Өйнең тәртибе калмады,
Әйтерсең пәри туе.
Һәркөнне мунча ягасы,
Көндә чиста кием кирәк.
Ярый әле машина бар,
Калмас иде ул беләк.
Телик карау онытылды,
Телефон оныкларда.
Этләр булып арый әби,
Иртән ята йокларга.
Ә иртәсен шул ук мәхшәр,
Камыр кую,боткасы.
Ул арада чәен сорый,
Газиз карты,бабасы.
Пыштым гына сак-сак басып,
Атлап йөрешле өйдә.
Оныклар тәмләп йоклыйлар,
Очмый хәтта чебен дә.
Икәүләп чәйләр эчкәчтен,
Сорашкачтын хәл-әхвәл.
Плитә кыза,эш башлана,
Күрсәң искитмәле хәл.
Ә бүген ял,өйдә тынлык,
Оныклар китеп беткән.
Таба алмый әби яулыгын,
Оныклар җыеп киткән.
Урынында түгел ахры,
Башмагы,җон ноские.
И ходаем кая икән,
Бабамның каштан мае?
Урыныннан күчкән бар да,
Ничек эзләп табарга?
Эзләмәгән җире калмады,
Тыкканнар соң кайларга?
Үзе эчтән генә сүгеп,
Күңеленнән сагынып.
Тәртип сала әби өенә,
Оныкларын юксынып.
Исән-сау гына булыгыз,
Көтеп каламын сезне.
Я,әбиләр,әйтегезче,
Таныйсызмы үзегезне?!

Гөлназ Шәрипова







# Тел, әдәбият, сәнгать өлкәсендәге яңалыклар

**ШИГЪРИЯТ**

Язуч

Факил Сафинга-70 яшь!






## Факил Сафинга-70 яшь!

ы, шагыйрь, фән һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты, филология фәннәре кандидатыГабдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Факил абый Сафинга — 70 яшь! Әдипне күркәм юбилее белән котлыйбыз! Яңадан-яңа уңышлар, сәламәтлек, иминлек, шәп кәеф телибез.



**Туган телдә җырыбыз**

Кояш кебек кадерле,
Туган җир – ул бер генә.
Туган илдә безнең җырлар
Яңгырасын гел генә!

Туган телдә җырыбыз,
Матур да соң көебез!
Әйдә, дуслар, бергәләшеп,
Җырлый-җырлый биибез!

Кояшка гөл үрелә,
Дөнья нурга күмелә.
Туган илем, Туган телем
Якын, газиз күңелгә.

Аяз булсын күгебез,
Якты кояш көлсен гел.
Туган илем, Туган җирем
Тыныч-имин булсын гел.

Туган телдә җырыбыз,
Матур да соң көебез!
Әйдә, дуслар, бергәләшеп,
Җырлый-җырлый биибез!




**Факил Сафин**

Бәхет нәрсә ул?
Бәхет нәрсә? Бу сорауга
Өлкәннәр җавап эзли.
Әйтерсең, дөрес җавапны
Беркем дә чынлап белми.
Әтием эшкә бара,
Әни озатып кала.
Мин йөгерәм мәктәпкә,
Бу да бәхет, әлбәттә!
Мәктәптән кайтып керсәм,
Бәйрәм бит безнең өйдә:
Бабай көлеп каршылый,
Кочып ала әби дә.
Әти, әни, бабай, әби,
Өстәлдә кайнар коймак.
Көйсезләнми энем дә,
Ул бүген артык тыйнак.
Гаиләдә татулык,
Тыныч бездә, күңелле,
Һәрбер көннең ямен күреп
Яшәү бәхет түгелме?!
Туган телдә сөйләшәбез,
Әби дога өйрәтә.
Намазга баскан бала мин,
«Бәхетсез», дип кем әйтә?..
Күл буенда бакчабыз,
Безгә монда эш күптер.
Бер файдасыз көн үтми,
Беләм, бу да бәхеттер!
Кешеләргә гел елмаеп
Матур сүзләр дәшәбез.
Үз илебез, үз җиребез,
Үзебезчә яшәрбез!
Бәхет нәрсә? Уйлый калсаң,
Җавапны күпләр белә.
Бәхет хакында уемны
Үземчә әйттем менә.


Язучы Факил Миңнемөхәммәт улы Сафин (әдәби тәхәллүсе – Факил Әмәк) 1954 елның 2 гыйнварында Татарстанның Мөслим районы Әмәкәй авылында туа.Кечкенәдән әдәбият-сәнгать белән кызыксынып үсә. 5 нче сыйныфта укыганда, шигырьләр яза башлый.

Ф.Сафин – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән, беренче әсәрләре белән үк укучыларның игътибарын яулап алган үзенчәлекле прозаикларның берсе. Ул – «Соңгы көз» (1989), «Гөлҗиһан» (1994) повестьлары, «Биек тауның башларында» романы (1999), «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе (2002), «Шәүлә» романы, күпсанлы хикәяләр, публицистик язмалар, шигырьләр, эпиграммалар, пародияләр һәм күп кенә язучыларның иҗатларына багышланган фәнни-тәнкыйди мәкаләләр авторы.

Ф.Сафинның җыр-музыка өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Шәһәр үзешчән композиторлары арасында ул, беренчеләрдән булып, Казанда Татарстан Президенты аппараты һәм «Җыен» фонды үткәргән балалар җырлары конкурсында, аннары Чаллыда үзе оештырышкан «Тургай» җыр фестивалендә катнашып, җиңү яулаган лауреатларның берсе була.

Ул шулай ук Чаллыда балалар иҗат түгәрәкләре, балалар өчен «Көмеш кыңгырау» исемле газета оештыру эшен дә башлап йөри. Ф.Сафин балалар язучысы буларак та билгеле. 1994 елда курчак театрлары өчен Ю.Чеповецкидан тәрҗемә иткән «Тычкангали һәм Мыраубәк» спектаклен яшь тамашачылар яратып кабул итәләр. Үз вакытында Чаллы Язучылар оешмасы рәисе урынбасары, «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсе җитәкчесе (1999–2002) буларак та Ф.Сафин яшь әдәби көчләрне тәрбияләү эшенә үзеннән зур өлеш кертә.









# Шәп ХӘБӘРЛӘР

*Заман миңа : "Югарыга мен "-дип,*
*Ике канат биреп үстерде.*
*Канатымның берсе-татар теле,*
*Икенчесе-бөек рус теле. Ә.Ерикәй*

## Котлыйбыз! Поздравляем!

Муниципаль олимпиадалар тәмамлангач, укучылар кышкы каникулларда ял иткәч, Республика күләм олимпиадалар башланды. Һәм менә 6а сыйныфында укучы Ильясова Эльвина Казан шәһәрендә инглиз теле буенча олимпиадада катнашып, безнең мәктәпнең данын яклап кайтты. Эльвина Республика этабында призер булды.

Без Эльвинаны һәм аның укытучысы Фархутдинова Алсу Накиповнаны уңышлары белән чын күңелдән котлыйбыз. Киләчәктә дә зур уңышлар телибез.

Без сезнең белән горурланабыз!













***Ильясова Эльвина стала призером Республиканского этапа Всероссийской олимпиады по английскому языку. Она учится в 6А классе. Скромная , учится хорошо. Обладает музыкальным талантом, хорошо***

***Мы поздравляем Эльвину и ее учительницу Алсу Накиповну, желаем дальнейших успехов!***

***Әфәрин!!!***





Безнең хәбәрчебез Әминә белән сез таныш инде. Әминәнең хыялы-журналист булу. Декабрь аенда Әминә Г.Акыш исемендәге Бөтендөньякүләм фәнни-гамәли конференциядә катнашты. Ул “Интернет-журналистика” дигән темага эш язды һәм II дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде. Без Әминәне һәм фәнни эшнең җитәкчесе Таҗиева Рузалия Равгатовнаны уңышлары белән котлыйбыз. Киләчәктә дә җиңүләр телибез! ӘФӘРИН ,ӘМИНӘ!




Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова Ләлә Хәкимовнаны да уңышлары белән котлыйбыз. Ләлә Хәкимовна Ф.Сафин исемендәге төбәкара фәнни-гамәли конференциядә катнашып, II дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде.




## Гыйнвар аенда мәктәп ничек яшәде?

Бу айда... 9,11 нче сыйныф укучылары Бердәм Дәүләт имтиханнарына әзерләнделәр, төрле фәннәрдән сынау бирделәр

Бу айда... Башлангыч сыйныф укытучылары Республика дәрәҗәсендәге семинар үткәрделәр. Семинарда ачык дәресләр, мастер-класслар күрсәттеләр.

Бу айда... бик күп кар яуды. Укучылар рәхәтләнеп мәктәп ишегалдын кардан чистарттылар.

Бу айда...ЮХИДИ инспекторлары укучылар алдында юл йөрү кагыйдәләре буенча лекцияләр үткәрделәр.

Хәбәрчебез Әминә студентлар көне уңаеннар төрле сыйныф укучылары белән әңгәмә үткәрде.




## Җәй истәлекләре.

Быел, җәйге каникул вакытында мин авылга кайттым. Авылда, үзегез беләсез, эш бик күп. Бигрәк тә авыл көтүен көтү бик җаваплы эш. Шулай итеп, без көтүгә чыктык. Анда бик кызык бер хәлгә очрадым. Карасам, ике тәкә бик каты сөзешәләр, бер-берсен һич тә кызганмыйлар. Мин хәтта куркып калдым... Нишләргә?



Мин нишләргә белмичә аптырап торган арада, тәкәләр бер-берсенең мөгезенә эләгешеп калдылар. Алар бер якка да китә алмадылар һәм рәхәтләнеп җирдә аунаштылар. Мин дә кыюланып киттем, карап торып булмый бит инде: барып, бер тәкәне күтәргән идем, тәкәләр, бер-берсеннән ычкынып, төрле якка чаптылар.

Быел без ике тапкыр көтү көттек. Икенчесендә дә кызыклы хәлгә очрадык.Көтүебез, тынычланып, бераз туктагач, әти су буена балык тотарга төшеп китте. Мин дә мотоцикл белән яр кырыена килеп туктадым. Билгеле инде, әти янына төштем. Әти бераздан: «Нинди ат килә анда?» дип сорады. Борылып карасак, мотоцикл әкрен генә ярга якынлаша. Шул арада мотоциклыбыз туп-туры суга очып килеп төште. Әти белән икебез, бер сүз әйтмичә, суга сикердек тә мотоциклны сөйрәп чыгардык... Аһ-ух килеп күтәрелеп карасак, безнең көтүебез басуга таралып беткән... Ул чакта безгә көлке түгел иде. Ә хәзер, көлешә-көлешә, шул вакыйганы искә алабыз.

Көтү көтүе авыр булса да, бик кызык, рәхәт икән ул: сыер мөгрәгән, сарык бәэлдегән тавышларны тыңлап, кара әле, болар татарча да аңлыйлар ахрысы, дип гаҗәпләнеп утырасың! Хуш исле яшел чирәмгә ятып, шәһәрдә яшәп игътибар ителмәгән чиксез зәңгәр күк йөзен күзәтәсең. Тирә-якта төрле кошлар сайрый... Әй, күңелле дә соң ямьле җәй айлары!

**Имамов Дилшат, 11нче Б сыйныф укучысы**

## 4 нче Г сыйныф укучыларыннан "Кызык-мызык" хикәячекләр



Камилә күршесе Кәримгә кунакка керде. Кәрим кәнәфигә кунаклады. Камилә күршесе каршына кәнфит куйды. Кәрим кунактан канатланып кайтып китте. Күршесе канәгать калды. Кәримне күрше кәҗәсе каршылады. Кәрим куанды, кәҗәгә кишер каптырды .Г. Ләйлә.





*Без бабай белән базарга бардык. Барганда безне бер бозау басуга борды. Басуда безнең ботинкалар балчыкка буялды. Бабай базарга бүтән бармаячагыбызны белдерде. Х.Эльвина*

Бездә “Балкыш”балалар бакчасы бар.
Балалар бу бакчага балкып баралар.
Балкыган балалар бик бәхетле була.
М.Султан



Кыш килде, көннәр кыскарды. Күбәләк- күбәләк кар керфекләргә куна. Куакларга кунган кышкы кунакларыбыз- кызылтүшләр күркәм күренә. Кешеләр кунакларга карап, канәгать калалар.
Ф.Алинә



“Яшь каләмче” түгәрәге. Редактор Таҗиева Р.Р.